ФИРДӘВЕС
ӘҺЛИУЛЛИНА

АК КҮГӘРЧЕН



ФИРДӘВЕС ӘҺЛИУЛЛИНА

АК КҮГӘРЧЕН

әкият-парчалар

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1990

ББҠ 84 (2Р-Тат)-4
Ә 99

ҠЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘҠТӘП БАЛАЛАРЫНА

Әһлиуллина Ф. Ә.

Ә 99 Ак күгәрчен: Әкият-парчалар.— Ҡазан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 47 бит.
ISBN 5—298—00153—X

Авторның яңа китабына тупланган әкият-парчалар балаларга да, олыларга да ошар. Алар кешеләрне бер-берсенә, табигатькә мәрхәмәтчел, ярдәмче булырга өндиләр.

Ә $\frac{\text{М 132(03)—90}}{\text{4803010200—090}}$ 177—89

ББҠ 84(2Р-Тат)-4

ISBN 5—298—00153—X

© Фирдәвес Әһлиуллина, 1990.
© Нияз Хажиәхмәтов, рәссам, 1990.



«Әкият ул балаларга гына түгел, ә бәлки олыларга да бик кирәк. Ул күңелдә бөек һәм кешелекле хисләр чыганагы булган дулкынлану тойгысын уята. Ул безгә тынычланырга ирек бирми һәм каршыбызда җем-җем итеп торган яңа киңлекләр ача, бүтәнчә яшәү мөмкинлекләрен күрсәтә, ул һаман да җанны бимазалап тора һәм бөтен хыялларыңның тормышка ашуын теләргә мәҗбүр итә. Аның кыйммәте нәкъ менә шунда...»

К. Паустовский

АК КҮГӘРЧЕН

Яшәгән, ди, булган, ди, Арслан исемле бер көтүче егет. Авылда Сөмбелә атлы өзелеп сөйгән кызы да булган, ди, Арсланның.

Көтүче егет көннәр буе җәйләүләрдә йөри, көтү көтә икән. Сөмбеләсен бик сагынган чакларда, үзе ясаган кураен алып, берсеннән-берсе моңлы көйләр уйный, ди. Сагынуын алай да баса алмаса, тиздән булачак туйлары турында уйлый, шул туйда сөеклесенә бүләк итәчәк мамык кәҗәсенә

соклана, аны сөеклесенә бүләк итүен күз алдына китерә икән.

Ниһаять, көзләр җитеп, туйлар да гөрләп үтә. Мәшәкатьләр бераз кими төшкәч, Сөмбелә сөйгәне бүләк иткән кәҗәнең мамыгын ала да, яза, эрли, аннары, чишмәгә алып төшеп, тал басмага басып юа. Кәҗә мамыгы искитмәле йомшак, ефәк кебек елкылдап торган ап-ак җепкә әйләнә.

Шуннан соң Сөмбелә, келәм тукып, йөрәгеннән ташып чыккан хисләрен шул келәмнең бизәкләренә салмакчы була. Җепне ул төрле үләннәрдән алынган мәңге уңмас, янып торган буяуларга мана, аннары уйга кала: нинди бизәк сайларга икән соң инде келәм өчен? Шулчак ул башын күтәреп тәрәзәгә карый һәм күктә очып йөргән ак күгәрченнәр көтүен күреп ала. Кадерле келәменә ак күгәрчен сурәтен төшерергә була кыз. Күңелемдәге иң изге, иң саф хисләремне сөйләсен, дип уйлый ул.

Көне-төне баш күтәрми эшли Сөмбелә. Һәм, ниһаять, эшен төгәлләп, келәменә карап алса, таң кала! Шундый тере, җанлы чыккан күгәрчен сурәте, менә-менә канатларын кагыныр да ачык тәрәзәдән очып китәр сыман!

Шул чагында әнисе Сөмбеләгә:

— Кызым, чишмәгә төшеп су гына алып менче! — ди.

Сөмбелә, ак күгәрчен белән аерыласы килмәсә дә, көянтәчиләген ала. Ишектән чыкканда да һаман борыла-борыла келәмдәге күгәрченгә карый.

Болдырга аяк басуы була, көянтәсенә бер кош килеп куна. Исе китә Сөмбеләнең: ак күгәрчене ич бу аның!

Алар бергәләп су буена төшеп китәләр.

Тора-бара күгәрчен кызның иң якын дустына, сердәшенә әверелә. Сөмбелә аңа үзенең мәхәббәте, Арсланны өзелеп сөюе хакында сөйли...

Көтмәгәндә-уйламаганда илгә афәт килә. «Сугыш башланган» дигән хәбәр авылга бик тиз таралып өлгерә. Ир-егетләрне яуга чакырып быргы уйный. Лачындай егетләр, атларга атланып, яу кырына китеп баралар. Сөмбелә дә Арсланы белән хушлаша. Шушы көннән аның йөрәгенә юксыну кереп урнаша.

Көннәрдән бер көнне хат ташучы аңа авыр хәбәр алып килә. «Иркәң яу кырында батырларча һәлак булды»,— дигелгән була ул хатта. Сөмбеләнең йөрәге ярылыр чиккә җитеп

тибә башлый, өзгәләнүләренә чик-чама булмый анық. Кинәт кызның иңенә бердәнбер юатучысы — Ак күгәрчен килеп куна.

— Өметнең чаткысы да калмады күңелемдә,— ди Сөмбелә, елый-елый. Аннары, бераз тынычлана төшкәч, болай дип сүз башлый:

— Әйтче, күгәрченкәем, кемнәр генә уйлап чыгарды икән бу сугыш дигән нәрсәне? Минем шикелле кыз-хатыннарның сөясе, сөеләсе, балалар үстерәсе килмимени? Минем Арсланым кебек япь-яшь ир-егетләрнең сугыш кырында ятып каласы киләмени?! Чал чәчле миллионлаган аналар балаларына бары тик бәхет кенә теләмимени? Кем башлады икән соң бу сугышны? Чал чәчле анасы да, сабый баласы да юк микәнни ул юньсезнең?

Их, күгәрченкәем, әгәр дә синеке шикелле канатларым булса, илдән илгә очар идем дә, очраган бер кешегә: «Әйдәгез, тыныч яшик!» — дип әйтеп йөрер идем. Бездән соң да яшисе кешеләр бар бит әле...

Шул вакыт күгәрчен Сөмбеләнең колагына нидер гөрләп куя.

— Әйе, әйе,— ди Сөмбелә.— Оч, сөйлә кешеләргә, сине һәммәсе дә бик яхшы аңлар!..

Көннәр, айлар, еллар үтә. Күктән күзен алмый Сөмбелә, һаман күгәрченен көтә. Гомер үтү белән ул картая, йөзен җыерчык баса, чәче дә күгәрчен канатыдай ап-ак була. Ниһаять, аңа да озын юлга чыгар вакыт җитә. Янына ахирәт дуслары, күршеләре җыелыша. Һәммәсе белән хушлашып, бәхилләшеп чыга карчык. Әмма үзе һаман нидер көтә, күзләрен бер дә тәрәзәдән алмый икән.

Бер заман төн уртасында ачык тәрәзә төбенә ап-ак күгәрчен килеп куна. Артыннан шундый ук ап-ак күгәрчен көтүе ияргән була.

— Гозереңне үтәдем мин синең,— дип гөрли Ак күгәрчен.— Бар илләрне гизеп чыктым, күп дуслар очраттым. Берсе белән бигрәк тә дуслашып киттек, безнең балаларыбыз булды. Алар барысы да синең янда. Аннары без бергәләп илдән илгә очып йөрдек. Шакымаган тәрәзәбез, сөйләшмәгән кешебез калмады. Алар безне аңладылар. Тынычлыкны сакларга вәгъдә иттеләр,— ди күгәрчен һәм, очып барып, келәмгә куна да яңадан мәңгелек сурәткә әверелә.

МӘК ЧӘЧӘГЕ ҺӘМ ТИГӘНӘК

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Күз яшьләрең түктең син шуңа...

Язын чәчәк аткан гөлләрнең барысы да көзен орлыкларын җиргә сибеп калдыра. Әлеге Мәк чәчәгенең дә орлыгы, елга ярына төшеп, җиргә күмелгән булган.

Менә бер заман яз килгән. Кояш көлгән. Орлык тишелеп чыккан, аннары үсеп җитеп, бөреләнгән. Иң кыены чәчәк ату булган аңа. Ниһаять, ул кызыл күлмәгенең итәкләрен таратып җибәргән.

Иң элек ул сулга караган. Анда ике соры таш ята икән. Чәчәк, танышмакчы булып:

— Әй, исәнмесез! Исемегез ничек сезнең? — дигән.

Ләкин ташлар җавап бирергә уйламаган да, ишетмәмешкә салынган. «Җирне бизим дип күпме тырыштым, ә минем белән сөйләшергә дә теләмиләр»,— дип уйлаган Мәк чәчәге, рәнҗеп.

Кинәт ул кемнеңдер карлыккан тавыш белән йөткерүен ишеткән. Борылып караса, күзләрен тутырып басып торган Тигәнәкне күргән. Бераз исен җыйгач, Мәк чәчәге Тигәнәк белән кыюсыз гына исәнләшкән. «Бигрәкләр дә ямьсез, бигрәкләр дә иләмсез инде. Үзенә күрә чәчәк атып маташкан булган бит әле, бичара»,— дип уйлаган Мәк чәчәге.

— Йә, ничек? — дигән Тигәнәк калын тавыш белән.— Тууын тугансың да, ничек кенә яшәрсең икән соң инде син?!

«Абау, нинди дорфа сөйләшә. Үзенә күрә түгел»,— дип уйлаган Мәк.

— Син әле сабый гына, җитмәсә, кирәгеннән артык матурсың,— дип дәвам иткән Тигәнәк.— Каян җыеп бетердең син бу төсләрне?

Мәк чәчәге, көязләнеп:

— Шулхәтле дә газапландым инде... Кыш буе җир астында яту җиңел дип беләсеңме? Аннары җирне тишеп чыгулары, Кояшка таба сузылулары... Зинһар өчен, исемә төшермә!..

— Син хәтта Кояштан да гүзәлрәк. Кояш ул түп-түгәрәк бер шар гына, көн буе күктә йөзеп йөрүен белә. Җитмә-

сә, яндырган, көйдергән чаклары да булгалый. Ә син... син нәфис, син назлы... Син — җирдә, янәшәдә. Сиңа хәтта орынып та була. Ачуланмасаң...

Мәк чәчәгенә мактау сүзләре яудыру Тигәнәккә әйтеп бетергесез ләззәт бирә икән.

да юк,— дигән Мәк чәчәге, еларга җитешеп.

— Кайгырма, дуслар табылыр ул. Дусларың бик күп булыр синең. Беренчесе — менә мин! Ышанасыңмы син миңа?

— Өметләнәм инде,— дигән Мәк чәчәге.

Шул мәлне кинәт көчле җил искән. Яшен яшьнәп, күк күкрәгән. Сүзгә мавыгып, күкнең караңгылануын сизми дә калганнар икән.

Җил үлән-чәчәкләргә ябырылган, аларны айкаган-чайкаган, йолыккалаган. Тамырларын каерып, әллә кайларга алып китәрдәй кыланган. Мәк чәчәге өчен борчылып, Тигәнәкнең йөрәге ярылыр чиккә җиткән.

«Беренче көн генә яшәве бит әле»,— дип уйлаган ул, ә чәчәкнең үзенә болай дигән:

— Син курыкма, имә башыңны! Миңа таян. Минем саба-

— Тик шунысы кызганыч, әлегә минем бер генә дустым

гым каты, тамырларым көч җыйган инде.

Җилнең көчле итеп бер исеп куюы булган, Мәк чәчәге, куркуыннан оятны да онытып, кая сыенырга белмичә, Тигәнәк сабагына килеп сыланган. Шулай күзен йомып, шактый озак басып торган ул...

Ниһаять, давыл тынган. Кояш чыккан. Күкнең бер читеннән икенче читенә салават күпере сузылган. Мәк чәчәге юешләнгән, бөгәрләнгән күлмәген тәртипкә китерергә керешкән.

Тигәнәккә сиздермичә генә бер карап алгач: «Ә бу Тигәнәк дигәннәре бер дә алай сөйкемсез түгел икән,— дип уйлап куйган Мәк чәчәге.— Беренче карашка гына иләмсез тоелган икән».

— Әй, Тигәнәк, әйт әле, мин җиргә матурлык өләшер өчен яратылганмы? Әллә минем яшәвемнең башка берәр мәгънәсе бар микән? Син бит шундый акыллы, барысын да беләсең,— дигән Мәк чәчәге бераздан.

— Әйе, барысын да беләм, синнән дә купшыраклар юк түгеллеген дә беләм, гөлкәем,— дигән Тигәнәк.

— Ә-ә-ә, шулаймыни? Кемнәр соң алар?

— Әйтик, Гөлчәчәк,— дигән Тигәнәк.— Ләкин миңа син якынрак. Телисеңме, мин сиңа бөек бер серне чишәм? Бервакыт көз килер. Бу матурлыгыңны югалтырсың, шиңәрсең. Әмма син көзен җиргә сибеп калдырган орлыклардан бихисап күп яңа мәкләр үсеп чыгар язын, шулай итеп, син җирдә мәңге яшәрсең...

— Чынлап сөйләвеңме бу?!

Мәк чәчәгенең соңгы сүзләрен яр буйлап үтеп баручы кыз белән егет ишетмәгән. Кыз, күзе төшеп, Мәк чәчәген өзеп алган да чем-кара чәчләренә кадап куйган...

Дөньяда менә шундый хәлләр дә булгалый ул.



САНДУГАЧ ҺӘМ САЕСКАН

Борын-борын заманда кара урманда, юк, урманда түгел, карт имәннәр һәм өрәңгеләр шаулап утырган бик зур бер бакчада Сандугач яшәгән, ди.

Бакча зур булгач, анда Сандугач кына түгел, башка кошлар да яшәгән. Кайбер кошлар агач куышында, ә кайберәүләре малайлар ясап элгән такта ояларда көн күргән. Сандугач оясының кайдалыгын берәү дә белмәгән. Чөнки ул оясын кычытканнар белән уратып алынган гөлҗимеш арасына ясаган булган.

Башка кошлар гел кешеләр тирәсендә очып йөргән. Фонтаннардан сулар эчкән, коенган. Сандугачны беркем күрмәгән, чөнки аның каурыйлары бизәкле түгел икән. Алай һаваланырлык бернәрсәсе дә юк икән Сандугачның.

Дөрес, бик моңлы, дәртле итеп җырлый белгән Сандугач. Мәгәр аның җырын бик тә сизгер кешеләр генә ишетә алган. Бу бакчага һәр көнне саф күңелле кеше — шагыйрь килә

торган булган. Менә шул рәхәтләнеп тыңлаган инде Сандугачны.

Әмма Сандугач шагыйрь өчен җырламаган. Җырламый түзә алмаган ул. Әгәр дә җырлаудан туктаса, аның йөрәге, мәхәббәт белән тулып, ярылачак икән, ди.

Куе куаклар арасында яшеренеп аккан чишмә турында җырлаган Сандугач. Таң турында да җырлаган ул. Бигрәкләр дә өзелеп җырлаган җыры — якын дусты, сердәше, сөеклесе турында булган. Ә аның сердәшен исә, усал кешеләр тотып, читлеккә япканнар икән.

Җырларга көй эзләп интекмәгән Сандугач. Матур җиһанның һәр төсеннән, һәр тавышыннан, һәр өненнән тапкан ул көйләрне. Хәер, көйләрнең иң матурлары аның җанында, йөрәгендә яшәгән, ди.

Бакчада яшәүче кошлар, кичләрен бер аланга җыелып, алардан читләшеп, алар белән аралашмый яши биргән Сандугач турында сөйләргә ятратканнар.

— Ничек тамагы карлыкмый бу Сандугачның?— дип аптыраганнар алар.— Шулкадәр тырыша, соңгы мәртәбә җырлавы диярсең...

Саескан барысыннан да күбрәк сөйләгән. Чөнки ул Сандугачтан бик нык көнләшә торган булган. Үзенең дә Сандугач шикелле шөһрәтле буласы килгән. Бервакыт хәтта ул бер композиторның ачык тәрәзә төбеннән ноталар язылган бер кәгазь битен урлауга да барып җиткән. Тегеләй куеп караган ноталарны, болай куеп караган. Әмма барыбер юньле көй чыгара алмаган. «Ә бит Сандугач ноталар турында уйлап та карамый, нишләп әле көйләр аңа үзләре килә икән?» — дип гаҗәпләнгән Саескан.

Ниһаять, аның башына, Сандугачтан үч алырга кирәк, дигән уй килә, һәм ул: «Аның якын дусты, сердәше, Сандугачны ташлап, минем кардәшем Ала карга белән җылы якларга китте»,— дигән хәбәр тарата.

Сандугач тетрәнеп китә бу хәбәрне ишеткәч: моңлы җыры өзелә, һәм ул, әрнүенә түзә алмый, үлә.

Бакчада Сандугач җыры ишетелми башлый, дөнья күңелсезләнеп кала. Шыксыз, иләмсез көннәр килә җир йөзенә. Салкын җилләр исә, кояш болытлар артына кача.

Саескан сөенеп бетә алмый инде. «Сандугач бетте, юк

Сандугач! — дип такмаклый ул.— Хәзер миннән дә шәбрәк җырчы юк бакчада!»

Ләкин матур көннәрнең берсендә таң алдыннан тын бакчаны янә Сандугач сайравы уята. Вафат булган Сандугачның дусты, сердәше, читлегеннән ирекка ычкынып, бакчага кайткан икән, имеш. Сагынып-сагышланып шул сайрый икән. Куе куаклар арасында яшеренеп аккан чишмә турында җырлый ул. Таң турында да җырлый. Ә бигрәк тә өзелеп җырлаган җыры — якын дусты, сөеклесе турында була. «Аның белән мәңгегә аерылышсак та, минем йөрәгемдәге мәхәббәтем сүнмәде, сүрелмәде. Ул минем җырларымда яшәр, һичкайчан да үлмәс бөек могҗизага тиң мәхәббәт!»— дип сайрый икән ул.

Сандугач сайравын ишеткән кешеләрнең күңел түрләре яктыра. Алар да бик яраталар ялгыз Сандугачның җырларын һәм, отып алып, үзләре дә җырлый башлыйлар.

Ә Саескан, ачуыннан нишләргә белмичә, Сандугачны уздырмакчы булып, тыкыр-тыкыр килеп карый да, әмма кая инде ул Сандугачны уздыру!..

◆

ҮЛМӘС ГӨЛ

Ирекнең әнисе әле күптән түгел генә япь-яшь, чип-чибәр бер ханым иде. Әллә нәрсә генә булды шунда: ул кинәт картаеп, сулып, ябыгып китте. Хәзер инде әнә, үлем белән тарткалашып, түшәк өстендә ята.

Ирек — аның бердәнбер сөекле улы. Алты яшьлек малайның да газиз әнисеннән бүтән дөньяда бер генә якын кешесе дә юк. Әнкәсенең газапларын күреп, ул да өзгәләнә, ул да сызлана. Шулай ук әнисеннән мәңгегә аерылыр микәнни инде Ирек? Юк, юк, малайның моңа ышанасы килми. Әнисенең исеме дә Үлмәс бит аның.

Ничек кенә әнисенә ярдәм итәргә, ничек кенә үлемнән коткарып калырга үзен — малай көне-төне шул хакта баш ватты. Уйлана торгач, дуслары сөйләгән бер хикәя хәтеренә төште аның. Имеш, әнә тегендә, офык читендәге кара урман эчендә, туксан яшьлек бер әби яши икән. Тик аның йортын табу бик читен һәм хәтәр эш икән. Ул тирәдә бер сукмак эсәре дә юк, меңьяшәр имәннәр сакта басып тора, ә куе булып үскән куакларның ботаклары үрелеп-үрелеп беткән, ди. Аюлар, бүреләр, төрле җәнлекләр бихисап, ди, ул төбәктә, әмма алар бер-берсенә һәм Җиһан әбигә тимиләр, үзара дус яшиләр, имеш.

Шул Җиһан әби, гомере буе урманда яшәп, табигатьнең бөтен серләренә төшенгән, җан иярен хәтта үлемнән дә коткарырга өйрәнгән, ди.

Ирек, бүтән чарасы калмагач, тәвәккәлләп, Җиһан әби янына барырга булды. Тиз-тиз генә җыенды да, әнисенә әйтеп тормыйча гына, юлга чыкты.

* * *

Ирек инде байтак җир үтте. Менә ул бер биек тауның башына менде. Биредән кара урман, уч төбендәге сыман, ап-ачык күренеп тора иде. Бер заман ул урман авызына да килеп җитте һәм сәерсенеп тукталып калды. Урман аңа бик шомлы күренә иде. Шулчак күз алдына әнисе сөйләгән әкиятләрдәге Шүрәле, Су анасы килеп басты. Ләкин ул бирегә ни өчен килгәнен бик тиз исенә төшерде һәм, бөтен батырлыгын җыеп, урман эченә атлады.

* * *

Ирек, сагаеп, көзге урман авазларына колак салды, күзләрен тутырып, барлык төсләр белән бизәлгән агач яфракларына карады. Ялан тәпиләре белән сак кына басып барды да барды ул. Бармаклары арасына шоп-шома, салкынча ылыс энәләре кереп кысыла, аннары алар, нәни балыклар сыман, кире шуып төшәләр. Табан астында кипкән-бөрешкән яфраклар, әрнүле авазлар чыгарып, сыкрана-кыштырдый. Карлыккан тавышы белән бар урманны сискәндереп, вакыт-вакыт карга кычкырып куя. Иреккә кинәт бик ямансу булып китте.

«Кара урманны бик матур, әкияттәге сыман гүзәл дип сөйлиләр иде. Ә биредә шулай шыксыз икән! — дип аптырады ул.— Әнә күпме агачлар корыган, череп ауган. Бер җәнлек юк, бер кош күренми. Әллә көз булганга микән? Ә бәлки... урман үлеп барадыр?» — дигән уй телеп үтте Ирекнең җанын.

Ләкин ниндидер сихри көч малайны һаман алга әйди иде.

Кинәт аның күзләренә якты бер нур сирпелде. Ул, хәйран булып, туктап калды. Малай каршында түп-түгәрәк бер алан ачылып киткән иде. Алан дип әйтерлеге дә калмаган, хәтта бер үлән әсәре дә юк. Бары тик иң уртада, уттай янып, йөрәккә охшаган бер гөл балкып үсеп утыра иде.

Ирек бер мәл аңардан күзләрен ала алмый карап торды. Чәчәк аны үзенә дәшә, тарта иде сыман. Ирек, сихерләнгәндәй, алга атлады. Чәчәкнең янына ук килеп, каршына тезләнде, сокланулы карашын төбәп, аңа үрелде, сакланып кына яфракчыкларына орынды.

— Чү, сабыр ит, өзә күрмә,— дигән йомшак тавыштан сискәнеп китте Ирек. Борылып караса, өстенә алсу чәчәкле ак күлмәк кигән, маңгаена төшереп ап-ак яулык бәйләгән, кулына таяк тоткан, аркасына нәни капчык аскан бер карчыкны күрде.

— Бу үләннең исеме Үлмәс гөл булыр,— дип дәвам итте карчык тыныч кына.— Кайчандыр, бик күптән инде, алан шау чәчәктә иде. Исеме дә Үлмәс гөл аланы иде.— Әби тирән итеп көрсенеп куйды.— Ә менә хәзер исеме генә калып бара бугай. Бу гөл — иң соңгысы.

— Ә мин монда Җиһан әбине эзләп килгән идем.

— Ә нәрсәгә кирәк соң ул әби сиңа? — дип сорады карчык.

Малай, үзе дә сизмәстән, күңелендәгеен ачты да салды әби-

гә. Әнисенең авыруын да әйтте, үз кайгысы турында да... Берни яшермәде.

— Ярый, улым, күңелең саф, ниятең изге икән... Мин булам инде ул Җиһан әбиең. Бу гөл — әниеңнең кече сеңелесе бит. Аландагы башка гөлләрнең сулганын сизеп, синең әниең дә авырый. Бу гөл шиңсә, әниең дә яшәмәячәк. Сиңа бу соңгы Үлмәс гөлне коткарып калырга, аны үрчетергә кирәк...

* * *

Ирек авылдан чыгып киткәнгә нәкъ бер ел вакыт узды. Шул бер ел эчендә ул Үлмәс гөл язмышыннан башка берни турында да уйламады. Үлмәс гөлне саклап калу өчен күпме көч түкте, хезмәт куйды ул. Ару-талуны белмичә, йокысын, ашавын онытып, үсентене тәрбияләде: төпләренә, әллә кайлардан алып, йомшак кара туфрак ташыды, һаман йомшартып, су сибеп торды. Ул аны үзенең сулышы белән җылытырга да әзер иде.

Ниһаять, Үлмәс гөл дүрт орлык бирде. Аларны кадерләп саклап, икенче язны Ирек аланга утыртты, хасиятләп карады. Үсентеләр шытып, чәчәккә бөреләнде. Малай шатлыгының чиге булмады.

Ирек Җиһан әби йортында яши бирде. Бар уйлаган уе, бар сөйләшкән сүзе Үлмәс гөл турында иде, чөнки гөлнең язмышы газиз әнкәсенең язмышына бәйләнгән бит. Ә Үлмәс гөл яши, димәк, әнисе дә исән-сау, шуңа сөенеп бетә алмый иде малай.

Ике елдан соң Үлмәс гөлнең орлыклары байтак җыелды. Чәчәкнең язмышына куркыныч янамый иде.

Көннәрдән бер көнне Җиһан әби иртән түшәгеннән тормады. Ишарәләп кенә Ирекне үз янына дәшеп китерде дә болай диде:

— Улым, инде мин бу фани дөньядан бөтенләйгә китәргә җыенам. Шуңа кадәр сиңа әйтәсе сүземне әйтеп калыйм дидем. Әниең хакына син изге эш башкардың: Үлмәс гөл аланын коткардың. Син гөлләргә үз тиңең, дустың, кандашың итеп карадың, аларның тавышларын, тормышларын аңларга өйрәндең. Синең күңелеңдә мәңге шиңмәс Үлмәс гөл — табигатькә карата мәхәббәт чәчәк атты. Инде хәзер син минем урыныма каласың...— Шул сүзләрен әйтүгә, Җиһан әби күзләрен йомды.

* * *

Тагын бер ел вакыт үтте. Шул вакыт арасында бернинди хәбәр булмаса да, әнисенең сихәтләнә барганын йөрәге белән сизә иде Ирек, шуңа борчылмый, тыныч яши иде. Ләкин күңеле алдагы көннәрдәниндидер бер шатлыклы вакыйгага буласын сизенә иде. Ниһаять, андый көн, аның иң бәхетле көне, килеп тә җитте.

Яз көне иде. Кояшның таң нурлары Үлмәс гөл аланын яктыртты. Ул шау чәчәккә күмелеп утыра иде. Һәр гөл үзе бер кояш сыман, нур сирпеп тора. Нинди генә кош юк иде монда, нинди генә күбәләк юк иде! Алан төрле тавыш белән сайрап, төрле төсләр белән балкый иде сыман.

Ирек урман авызына чыкты. Еракта, авыл ягыннан килгән юлда, ул җил-җил атлап килүче бер хатын-кызны күрде. Ул Ирекнең әнисе иде. Ана канатланып, очынып атлый. Яшьлеге, чибәрлеге яңадан кайткан иде аңа.

Якынлашкач, алар бер-берсен кочаклап алдылар, сөйләшә-сөйләшә алан ягына атладылар.

Мондагы гүзәллекне күреп, әнисе «аһ» итте.

— Рәхмәт сиңа, улым,— диде ул, бәхетле елмаеп.— Чөнки син мине генә түгел, Үлмәс гөл аланын да коткарып калдың. Инде менә синең яныңа үзем дә килдем. Без синең белән бергәләшеп урманны яшәртербез, гөлгә күмәрбез...

◆

ҠАР ҠАТЛАМЫ

Биек таш кыя башындагы ап-ак Қар катламы менә инде ничәмә-ничә мең ел буена кояш нурларында җемелдәп ятуын белә. Үз гомере эчендә бар дөньяга өстән аска карарга күнеккән ул, ә үзеннән өстәрәк бары тик җиңел болытлар гына йөзгән.

Аста, үзәнлектә яшәүче кешеләрнең тормышы кайнап торган, алар туганнар, үскәннәр, аннары, яратышып өйләнешкәннәр дә, балалар тудырып, аларны аякка бастырганнар. Буыннан буынга күчеп килгән тагын бер шөгыльләре булган аларның: гаҗәеп зур һәм матур бакчалар үстергәннәр ул кешеләр.

Шулай итеп буыннар берсен берсе алмаштырып торган, тормыш үзгәргән, алга барган, бакча һаман зурайган, күкрәп үскән, һәр яз саен ап-ак шау чәчәккә күмелә торган. Бары тик таш кыя өстендә хәрәкәтсез яткан Қар катламы гына һич тә үзгәрмәгән: аны берни дә борчымаган да, дулкынландырмаган да.

Ләкин бер заман, яз көнендә, алмагачлар һәм чияләр ак чәчәккә төренеп утырган чакта, үзәнлеккә көтелмәгән зур афәт — корылык килгән. Эссе кояш нурлары җир йөзен мәрхәмәтсез рәвештә көйдергән-яндырган, айның-ай буена җир өстенә, ичмаса, бер генә тамчы да яңгыр таммаган. Алмагачлар, чияләр, корылыктан интегеп, корый, чәчәкләре шиңә башлаган.

Қар катламы моны белеп, күреп торган, билгеле, әмма тыныч кына, илтифатсыз гына: «Алга таба тагы ниләр булыр икән?» — дип көтеп торган.

Ә шулай да көннәрдән бер көнне салкын җанлы Қарга нидер булган: ул, далада өзелеп-өзелеп җырлаучы бер кызның чишмәдәй саф һәм нечкә тавышын ишетеп, таң калган, әсәрләнгән. Кызның җыры исә ак чәчәкле язгы бакча, инде хәзер беркайчан да өлгермәячәк җимешләр турында булган. Аның тавышы Қарга кинәт җан өргән кебек булган. Ул шулхәтле тәэсирләнгән ки, кыз өенә кайтып киткәч тә әле Қарның күңелендә аның тавышы бик озак яңгыраган. Ул, аның төшенә кереп, йокысыннан уяткан. Һәм, ниһаять, хәтеренә сеңеп калган шул искиткеч авазларны әкрен генә пышылдый башлаган Қар. Тора-бара бу җыр аның бәгыренә үк үтеп кергән, аны тәмам эреткән. Шуннан соң Қар, моңлагән

жырчы гөрләвекләргә әверелеп, челтер-челтер килеп, түбәнгә юл тоткан, бакчаларга таба агып киткән. Шул бакча янына янә килеп, моңланып утыручы кызның тавышын якыннанрак ишетергә теләгән ул.

Аннан күрмәкче, бүтән кар катламнары да, мәңгелек йокыларыннан уянып, шул үзәк өзгеч көйнең аһәңнәрен ишетү белән, шулай ук әкренләп эри башлаган. Таудан шаулап агып яткан кар сулары барысы бергә кушылган да гайрәтле бер дәрья тәшкил иткән. Ул дәрья, ниһаять, үзәнлеккә төшеп җиткән, киң җәелеп, талгын гына агып киткән. Бакча яныннан гына агып яткан бу елганың сулары алмагачларның һәм чияләрнең сусаган тамырларын да сугарып узган. Алар яшәреп, ямьләнеп киткәннәр.

Җырчы кыз, елга ярына килеп, рәхмәтен җыр белән әйтеп биргән. Бар табигать аңа кушылып җырлаган бу гүзәл көйне.

«Ярый әле эредем,— дип шатланып уйлаган йөгерек дулкыннарга әверелгән Кар.— Гасырлар буе бернинди хәрәкәтсез ятуга караганда, бер генә мизгел булса да гөрләп яшәп калуың мең өлеш артык икән! Менә хәзер инде үлсәм дә үкенмәм...».

Әмма ул яшәвен дәвам иткән, үлмәгән. Су юлы корымаган, кипмәгән. Табигать елның-елында һаман яшәрә, яңара торган. Карлар яуган, таш кыялар өстенә катлам-катлам булып ята торган, эри торган. Аннары алар, мәңге тынмас җырның тылсымлы авазларын ишетеп булса кирәк, әкренләп эреп, җырчы гөрләвекләргә әверелгән дә, түбәнгә төшеп, үз суларын мул сулы елгага куша торган...

ЯШЬ БӨРТЕГЕ

Яшәгән, ди, дөньяда Язилә исемле бик усал бер кыз. Ул шулхәтле явыз, шулхәтле дорфа һәм үзсүзле булган ки, барлык авылдашларын да, хәтта әти-әнисен дә бертуктаусыз елатып торган, ди. Бик әче телле булган инде менә. Ә үзенең күзләреннән ник бер генә күз яше тамып карасын, ди, кызның. «Мин сезнең барыгызны да җиңәм, мин сезнең барыгыздан да көчлерәк!» — дип көлә генә икән тегеләрдән.

Шулай итеп бөтен авыл халкы көне-төне кызыннан зарлангач, Язиләнең әнисе дә уйга калган, хафага төшкән. «Нинди гөнаһларым гына булып, ни өчен генә мине ходай тәгалә шулай каргады икән?»— дип өзгәләнә башлаган бу.

Язиләнең әнисе, чыннан да, бик йомшак күңелле, бик шәфкатьле кеше булган, ди. Әмма, уйлана торгач, аның да яшь чакларында, яшьлек юләрлеге белән кылынган бер хатасы «кылт» итеп исенә килеп төшкән. Исенә килеп төшкән дә утларга ук салган ананың йөрәген.

...Ул чагында Язиләнең әнкәсе Әнисәгә унбиш яшь тә тулмаган булган шул әле. Көннәрдән бер көнне ул, чиләк-көянтәсен ала да, чишмәгә төшеп китә.

Гаҗәеп матур урынга урнашкан аларның авыллары! Чишмәләре дә искитмәле! Тау итәгеннән генә бәреп, җанлы йөрәк сыман «дөп-дөп» итеп тибеп тора сыман ул зәп-зәңгәр Чишмә. Тик менә бүген аңа нидер булган төсле. Суы тоташ агым булып түгел, сулкылдап типкән сыман гына ага...

Әнисә, тар басмага басып, чиләкләрен тутырып су ала да кайтыр юлга борыла. Шулчак Чишмә кинәт телгә килә һәм ялынып-ялварып кыздан ярдәм сорый башлый.

— Туганкаем, бәгырькәем, коткар мине,— ди Чишмә.— Зинһар, дим, ярдәм итә күр... Җир асты диюе мине зәңгәр итәгемнән эләктереп алды да хәзер үзе янына, җир астына сөйрәмәкче була. Күреп торасың, мин барлык көчемә карышам, ләкин аңа каршы торуы миңа бик читен. Ярдәм ит, сеңелем, ичмаса, авызымны киңрәк итеп ачып, чистартып җибәр! Изгелегеңне мәңге онытмас идем.

Чишмәнең сүзләрен игътибар белән тыңлап тора Әнисә, аның зары йөрәгенә дә үтә кебек, әмма яшьлек гамьсезлеге көчле була шул: «Тиз генә суны өйгә кайтарып килим дә шун-

нан соң иркенләп эшләрмен...» — дип уйлый ул ваемсыз гына. Моның ни белән бетәсен күз алдына да китерми, билгеле.

Өенә кайткач, тагын әллә нинди яңа мәшәкатьләр килеп чыга, йорт эшләре белән мавыгып китеп, Чишмәнең гозерен кичкырын гына, инде караңгы төшә башлагач исенә төшерә Әнисә. «Ярый инде, иртәгә иртүк, ял итеп торгач барырмын, гафу үтенермен Чишмәдән...» — дип уйлый ул йокы аралаш.

Ләкин иртән, чиләк-көянтәсен күтәреп, суга баргач, Чишмәне тапмый ул, әле кичә генә шактый мул булып су агып торган урын да бөтенләй кипкән, корыган була.

Шулай итеп, моңарчы авылга ямь биреп торган Чишмәнең суы кинәт кенә юкка чыга.

Беркемгә берни әйтми Әнисә, үз гаебен авылдашларыннан яшерергә тырыша, кичермәсләр дип курка. Сәбәбен белә торып та, Чишмәне коткару юлын кешеләргә әйтми. Халык корылыктан иза чигә, мал-туар кырыла, игеннәр көя. Торабара иген кырларын тоташ ком басып китә. Шуннан соң инде авылдашлары, би-ик тирән бер кое казып, шуңа бик күп хезмәт һәм көч түгеп, эчәр өчен генә суны шуннан ала башлыйлар...

Үзенең яшьлектәге гаебен исенә төшереп, бик уфтанган Әнисә, тәмам йокысы качкан. Өч көн, өч төн рәттән уйлангач, дүртенче көнне, таң беленер алдыннан, кызын уяткан да үз гаебен сөйләп биргән. Сүзен болай дип түгәрәкләгән: «Инде хәзер син әниеңнең дә гаебен юарга, үзеңнең дә күңелеңне төзәтергә, авылдашларыңа да суны кайтарып бирергә тиешсең. Миннән сиңа фатиха!» — дигән.

Кыз, әлбәттә, бик үпкәләгән әнисенә, «Ни өчен әле мин синең гаебеңне юарга тиеш?» — дип, яман да ачуланган. Әнисен каһәрли-каһәрли, мәңге әйләнеп кайтмаска антлар биреп, өеннән чыгып киткән.

Бара икән, бара икән бу, әмма күңелендә кузгалган ярсуы һаман басылмый икән моның. Җиде төн шулай бар дөньяны, әти-әнисен, авылдашларын сүгә-сүгә, тиз-тиз атлап барганнан соң гына кинәт тукталып калган бу. Туктап калып, тирә-ягына күз салса, үзенең әллә нинди таныш булмаган, ят җирләргә килеп чыгуын абайлап алган, ди. Тегендә бәрелеп караган кыз, монда сугылып караган, әмма кире кайтыр юлны таба алмаган, юкка чыккан, ди, аны бирегә алып килгән юл. Инде тәмам адашуын аңлап, тын калган Язилә. Инде хәле дә бетә

башлаган, ди. Шулчак әнисе пешергән тәмле-тәмле ризыкларны исенә төшергән кыз. «Әгәр исән-сау өйгә кайта алсам, гомеремдә дә әнине рәнҗетмәс идем, кадерләп кенә торыр идем»,— дип антлар эчкән ул. Шулай дип уйлап бетерүе булган, каршында гына, нәкъ аяк очлары янында әллә кая түбәнгә алып төшә торган бер баскыч күреп алган. Кая барырга белмәүдән, башка чарасы калмаган кыз шул баскычка аяк басарга мәҗбүр булган инде. Бик озак төшкән ул баскыч буйлап аска — җир астына. Аяк-куллары тырналып, җәрәхәтләнеп беткән моның, аяклары арудан атлый алмас хәлгә житкән. Аннары үрмәли-үрмәли алга бара биргән, күңеле дәшкәндер инде...

Җеп өзәрлек тә хәле калмагач, кинәт каршында ук дәү бер залның пәйда булуын күреп алган бу. Кайдандыр йомшак кына зәңгәрсу яктылык та сирпелеп тора, ди, үзе. Залның стеналары гел таш, бүлмә тирәли дә таш агачлар, таш чәчәкләр тезелеп тора, ди. Ә бүлмәнең урта бер җирендәге таш тәхеттә аяк-куллары, түшләренә кадәр ташка төренеп беткән ап-ак чәчле бер карчык утыра, имеш. Күзләре дә йомык икән, бары тик иреннәре генә, әкрен генә кыймылдап, нидер пышылдыйлар, сөйлиләр, ди. Колак салыбрак, игътибар беләнрәк тыңлап карагач, Язилә карчык авыз эченнән генә мыгырдаган сүзләрне ишетә, аңлый да башлаган сыман була.

— Маңгай күзләрем күрмәсә дә, күңел күзләрем бик яхшы күрә минем,— дигән ул.— Синең кем икәнеңне, бирегә ни өчен килгәнеңне сөйләп тормасаң да була. Син хәзер мине тыңла. Яхшылабрак тыңла, бер сүземне дә онытасы булма.

Менә мин — Су анасы булам. Җир асты дию минем кызым Чишмәне җир астына бикләп, аның кешеләр янына илтә торган юлын, җир асты юлын, үтә алмаслык итеп томалап куйды. Тыңлап кара әле, ишетәсеңме? Ничәмә-ничә еллар инде шулай бәргәләнә, шулай ыңгыраша, шулай елый бичара Чишмә... Берәр хәвеф-хәтәр булмаса ярар иде инде...

Менә мине дә, кызымны яклаган өчен, тимер богаулар белән шушы тәхеткә богаулап куйды явыз Гыйфрит. Кызым кайгысыннан елый-елый күзләрем сукырайды, инде елый да алмыйм, бер генә бөртек күз яшем дә калмады минем...

Су анасының шушы хәлләрне сөйләп бетерүе булган, Язиләнең йөрәге, гомер булмаганча, кинәт авыртып, чәнчешеп куйган. Күзләрен дә әллә нәрсә чеметтереп алган кебек, ан-

нан кайнар яшь бөртеге тамган. Су анасын чын күңелдән кызганып куйган бугай ул.

— Әгәр дә мәгәр минем кызым Чишмә, тоткынлыктан ычкынса, «әни» дип минем каршыма килсә, иманым камил, күзләрем ачылып китәр иде, мин яңадан күрә башлар идем. Шулхәтле көчле миндә аны күрү теләге! Кешеләр дә сөенерләр иде, мөгаен.

Язиләнең күңелендә кинәт яралган кызгану хисе әкренләп аның йөрәгенә үтә башлаган, ниһаять, бар җанын биләп алган.

— Ул Чишмәне ничек тә булса коткарып буламы соң? — дип сораган Язилә.

— Ник булмасын, була! Тик моның өчен күңеле бик йомшак, йөрәге шәфкатьле кеше кирәк. Югыйсә, Чишмәне дә коткара алмас, үзе дә харап кына булыр... Әгәр дә тәвәккәллисең икән, ә-әнә теге дәү йозакны барып ачарга кирәк. Йозак ачылса — синең бәхет, барыбызның да уртак бәхетебез...

Ике дә уйлап тормаган Язилә. Хәзер инде аның күңеле кузгалган, йөрәге уянган. Ул инде бүтәннәр кайгысын йөрәгенә үзенекенә караганда да якынрак кабул итү сәләтенә ирешкән.

Бар булган кыюлыгын җыеп, алга, дәү йозак белән бикләнгән тимер капкага таба атлаган кыз. Әмма йозак алай бик тиз генә бирешергә уйламаган. Тегеләй итеп караган кыз, болай итеп караган. Азаплана торгач, бармакларын да канатып бетергән. Тырнак астыннан саркып чыккан кып-кызыл канының бер генә тамчысы шул сихерләнгән йозакка тамган икән, ул шунда ук «шылт» итеп ачылып та киткән. Чишмәнең аһ-зарлары шунда ук тынган, ул, матур гына челтерәп, элеккеге юлын яңартырга дип, рәхмәтләр әйтә-әйтә агып киткән. Шул суның серле тавышын тыңлап, Язилә бер генә мәлгә күзләрен йомган икән, шунда ук яңадан үзенең туган авылына кайтканын, янә Чишмә буенда басып торуын абайлап алган.

Әллә кайчаннан бирле инде су чылатмаган чишмә авызыннан кинәт ургылып-ургылып су килә башлаган, мул сулы агым, инешкә әверелеп, зәңгәр тасма булып авылга таба агып киткән.

◆

ҠУРАЙ МОҢЫ

Яшәгән, ди, бер Ана. Аның бердәнбер юанычы, йөрәк парәсе, Илһам исемле сөекле улы булган. Ул бик чибәр: зәпзәңгәр күзле, озын куе керфекле булган, әмма бик бәхетсез — авырып, түшәк өстендә хәрәкәтсез ята икән.

Алар икәү яшәгән бердәнбер тар гына бүлмәнең бердәнбер тар тәрәзәсе дә кызыл кирпеч стенага карап, аңа терәлеп диярлек торган, ди. Бар җиһанны томалаган, ди, алардан шушы таш дивар. Ни Ҡояшны күрми яшәгән егет, ни Айны...

Ҡышкы озын төннәрне йоклый алмый изаланып үткәргән бахыр. Аның болай да боек күңелен гел-гел ачы сагыш биләп ала икән. Шундый минутларда ул бердәнбер юанычы, өмет чаткысы булган кураен кулына алган һәм берсеннән-берсе моңлы көйләр уйнап, озын төннәрен үткәреп җибәргән. Бу көйләрне кемдер ишетә дип башына да китереп карамаган Илһам. Ә аларны тыңлаучылар булган. Бу — таш дивар артында урнашкан зинданның тоткыннары икән. Алар, тимер рәшәткә тотылган бәләкәй генә тәрәзәләргә сарылып, дөньяларын онытып, шул сихри моңнарның тәэсиренә бирелгәннәр, ди. Күңелләре белән балачаклары узган туган авылларына, аның урман-күлләренә очып кайткандай булган алар. Берсе, йөрәге әрнеп, ялгыз калган карт анасын исенә төшергән, икенчесе — сөйгән ярын... Яшьлек юләрлеге белән кылынган хаталарын уйлап, җаннары сызган, бәгырьләре парә-парә телгәләнгән, ди, тоткыннарның. Шулай итеп таш дивар артыннан ишетелгән курай моңы аларның күңелләрен эреткән. Торабара алар шәфкатьлерәк, миһербанлырак булып киткәннәр, ди...

Язлар җиткән. Бичара карт Ана тәрәзәне ачып куйган да, улына: «Ичмаса, диңгез һавасын сула, балам, бераз шифасы булмасмы?..— дигән.— Диңгез янәшәдә генә булса да, сине анда алып бару минем хәлемнән килми шул. Югыйсә, бәлки инде күптән сихәтләнгән булыр идең...»

Беркөн шулай Илһам иртүк уянып киткән: кояшның бер нуры, аның йөзенә төшеп, керфекләрен кытыклап уяткан икән.

«Ә кайдан төшә соң бу кояш нуры?» — дип, тәрәзәгә караса, таң кала егет: таш дивар юк, ә элек шул стена торган турыда, зәп-зәңгәр күктә Ҡояш балкый, ди!

Ничек итеп яткан урыныннан торып, бернигә дә тотынмыйча тәрәзә янына барып басканын үзе дә сизми кала егет. Биредән аңа әйтеп бетергесез гүзәл манзара ачыла. Кояш нурларында иркәләнеп, диңгез җәйрәп ята; тирә-юньдә хуш исләр аңкый; дөнья әйтерсең лә ап-ак чәчәктә коена!

Егет шулай әсәрләнеп карап торганда, бүлмәгә әнисе килеп керә һәм, тәрәзә янында басып торган малаен күреп, аптырап кала, аннары, шатлыгыннан акылын җуяр дәрәҗәгә җитеп: «Бу нинди могҗиза, улым?!» — дип тәкрарлый-тәкрарлый, улының иңнәренә килеп сарыла.

Илһам, тынычландырырга тырышып, аның кулларыннан, чәчләреннән сыйпый.

— Әни, мин тәмам сәламәтләндем. Хәзер инде бар эшне дә үзем эшләрмен, сиңа җәфаланырга туры килмәс бүтән. Карт көнендә бераз ял итсәң дә ярыйдыр,— ди ул.

Алар шулай сөенеп тәрәзәдән аска карап торган чакта, әллә каян гына бер төркем балалар килеп чыга. Алар, җирне казып, түтәлләр ясыйлар һәм чәчәкләр утырта башлыйлар.

— Әй, энекәш,— дип эндәшә Илһам бер балага,— биредәге таш дивар кая китте соң әле?

— Аны бүген төнлә сүтеп ташладылар. Тоткыннар әйбәтләнгәннәр, аларны иреккә чыгарып җибәргәннәр. Безнең шәһәрдә хәзер бер генә дә явыз кеше калмаган икән. Шуңа күрә, зинданның кирәге калмады дип, аны җимереп ташларга, ә урынына чәчәкләр утыртырга булдылар,— ди теге бала.

— Йә әле, сез эшли торыгыз, ә мин сезнең күңелегезне күрим, курайда берәр матур көй уйныйм,— ди Илһам һәм, кураен алып, иң яраткан көен уйнап җибәрә.

ТӘҢКӘБИКӘ

Яшәгән, ди, Дамир исемле бер малай. Аның әти-әнисе бик хәлле кешеләр булган, бик бай яшәгән, ди. Әмма бөтен маллары хәләл көч белән, намуслы хезмәт белән табылганга күрә, аларның күңелләре саф, чиста икән. Тик менә малайлары Дамирның акчаны артык яратуы, акча җыю белән артык мавыгуы гына ата-ананың күңелен бертуктаусыз борчып торган, ди. Җитмәсә, таныш-белешләре дә, туган-тумачалары да, малайның комсызлыгын, үтә саранлыгын күреп тә, аңа һаман әле бер нәрсә, әле икенче нәрсә бүләк итеп, аның күңелен боза килгәннәр. Бервакыт берәүләр хәтта акча җыю өчен махсус ясалган тишекле тартма да бүләк иткән, ди, аңа. Менә шуннан башланып киткән дә инде ата-ананың барлык газаплары. Берәр кеше аларга кунакка киләме, үзләре кемнәргәдер кунакка барамы — кайда гына, кайчан гына булмасын, малайлары һәркемнән һәрчак акча өмет итә, акча сорый торган булып китә. Шулай итеп, көннән-көн комсызлана бара малай.

Тырыша торгач, Дамирның тартмасы тулып та җитә. Аңа

бары тик бер генә тимер акча саласы кала. Шуны сала да, тартманы ватып, андагы барлык акчаны алып, дөньяда иң бай, иң беренче малай була ул! Шундый була малайның хыялы. Ләкин, үч иткәндәй, ул арада беркемнең дә Дамирга акча биргәне булмый. Ә малайның күңеле һаман кымырҗып тора. Шуннан соң, бик озак уйлап, баш ватканнан соң, бер җаен уйлап таба Дамир: әнисенең акча янчыгыннан, беркемгә сиздермичә генә, бер көмеш тәңкә алып торырга була. Моны һич тә гаепкә санамый ул. Әмма нинди коточкыч начарлык, ялгышлык эшләгәнен малай соңыннан гына төшенә. Әнисенең янчыгыннан сораусыз алган көмеш тәңкәне тартмасының тишегенә төшерүе була — малайның күзләренә кинәт ниндидер сәер ут көлтәсе бөркелгәндәй була, ул ут малайның күзләрен авырттырып, яман чәнчеп ала. Дамир түзә алмый, ике кулы белән йөзен каплый. Ә бераздан күзен ачып җибәрүе була — үзенең әллә нинди ялан кыр уртасында япа-ялгыз басып торуын абайлап ала. Нәкъ аның каршында гына оз-ы-ын бер юл сузылып ята икән. Ни чарадан бичара дигәндәй, малай шул юлга аяк басарга мәҗбүр була, әйдә, кая да булса илтер әле, ди.

Бик озак бара малай юл буйлап. Бара торгач, өстенә ишелергә торгандай биек таш пулат каршына килеп чыга. Шул мәлне пулатның ишекләре тавышсыз-тынсыз гына як-якка ачылып китмәсенме! Дамир кыяр-кыймас кына алга атлый, бина эченә керә, аннары ап-ак мәрмәр баскычтан икенче катка менә дә искитмәле матур, иркен залга килеп керә. Ул бүлмәдә кояш үзе балкып тора диярсең! Стеналардагы алтын бизәкләрдән Дамирның хәтта күзләре чагылып китә. Бераз иләшә төшкәч, бүлмәнең урта бер җирендә алтын тәхеттә утыручы бер ханымны күреп ала малай. Аның кыйммәтле парчалардан тегелгән аксыл күлмәкләре уттай янып, елкылдап тора икән.

— Исәнме, Дамир,— ди ул алтындай чыңлап торган тавышы белән.— Мин — Тәңкәбикә апаң буламын. Бөек Тәңкә иленең бөек хуҗасы. Уз әйдә, утыр бирегә, минем яныма,— ди ул, янәшәсендә торган тәбәнәк урындыкка күрсәтеп.— Тиздән ирем Сәмән дә кайтып җитәр, бергәләп алтын тәңкәләрдән әзерләнгән чәй эчәрбез. Ә аннары... Аннары безнең тиңсез хәзинәләребез белән танышып чыгарсың... Беләсеңме, без ирем Сәмән белән бик бай яшибез, үз гомеребездә би-ик күп

мал туплары. Улыбыз булыр, бөтен байлыгыбызны аңа калдырырбыз, дип уйладык. Әмма, гөнаһ шомлыгына каршыдыр инде, ходай безгә бала бирмәде...

Бәлки, синң бездә ошап китәр, боерган булса, бәлки, үзебезнең улыбыз булып кына калырсың бирерә?.. Әлбәттә, ошар, ошамый ни! Син бит шундый мал җанлы бала, син шундый саран, комсыз! Әниеңнең акчаларын сорамыйча алуга хәтле барып җиткәнсең икән, димәк, синең күңелеңә комсызлык чире кереп оялаган инде... Мин моны яхшы беләм!..— ди ул, хәйләкәр елмаеп.— Хәзер инде сиңа бу чирдән котылу бик кыен булачак, боерган булса. Җанына саранлык, комсызлык чире кагылган кеше өчен дөньяда акчадан да кадерлерәк нәрсә юк. Акча дигәндә, ул теләсә нинди түбәнлеккә, теләсә нинди әшәкелеккә барып җитә ала, аны берни дә туктата, тыя алмый. Ул бары тик баю, күбрәк акча туплау турында гына уйлый. Үзенең байлыкларын барлап, ул рәхәтләнә, бәхетле минутлар кичерә! Менә сине дә, улым, шундый бәхет, сәгадәт көтә. Сүземне тыңласаң, акыллы булсаң, мин сиңа бу юлда булышлык күрсәтә алам.

Малай сокланулы карашын Тәңкәбикә апасыннан ала алмый, озак уйлап тормыйча, мин риза, дип, башын кага.

Тәңкәбикә матур тавышы белән дәвам итә.

— Дөресен генә әйткәндә, син күптән инде минем колыма әверелә башладың. Мактыйм үзеңне!

Нәкъ шул чакны залның ишекләре киң итеп ачылып китә дә бүлмәгә тәбәнәк кенә буйлы, шартлар дәрәҗәгә җиткән дәү корсаклы бер зат килеп керә. Ул, Тәңкәбикә янына килеп, аның кулын үбеп ала, аннары, малайга күрсәтеп:

— Бу кем тагы? Чираттагы «улыңмы»? — дип сорый усал тавыш белән.

— Улым да булсын ди, йә нәрсә, әллә миңа да берәр юаныч кирәк түгел дип уйлыйсыңмы? Тере бер уенчык, дим... Ә бәлки, аңардан, чыннан да, рәт чыгып куяр?! Бигрәк тә саран, бигрәк тә комсыз инде, югыйсә!

Шуннан соң Тәңкәбикә, бәләкәй генә алтын кыңгыравын чыңлатып, кемнедер дәшә дә, бүлмәгә тиз-тиз атлап бер тимер зат килеп керә.

— Тимерҗан,— дип мөрәҗәгать итә аңа Тәңкәбикә.— Бар әле, күрсәтеп кайт әле шушы малайга безнең биләмәләребез-

не! Күрсен әле бер туйганчы, рәхәтләнсен әле! Тели икән — кесәләренә дә тутырсын, күпме алып кайта ала — алсын...

Шуннан соң Тимерҗан, тимер кулы белән Дамирның беләгеннән эләктереп, ишеккә таба алып китә. Аннары алар бинадан чыгалар да, почмактан борылып, өй артына узалар, тимер агачлар, тимер чәчәкләр үсеп утырган бакчаны кичеп, кырга чыгалар. Бик сәер булып тоела бу кыр Дамирга. Бодай башаклары урынына кырның бер ягында алтын тәңкәләр тагылган алтын башаклар күкрәп үсеп утырса, икенче яртысында Тимерҗанга ике тамчы судай охшаш тимер затлар яңа тәңкәләр чәчеп йөриләр икән.

— Менә, малай, күр инде син, соклан безнең байлыкларга,— ди Тимерҗан күтәренке тавыш белән.— Әйдә, алга уз, җыя алган кадәр җый, тутыр кесәләреңә! Бер дә тартынып торма. Алар бит монда үзеннән-үзе үсеп тора, өзелгән бер тәңкә урынына янәдән өч тәңкә үсеп чыга. Кая куярга да белгән юк инде менә.

Бу сәер күренешләрдән Дамирның кинәт башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып киткәндәй була. Биредә бер генә дә тереклек иясенең булмавы бик куркыта аны. Бу хакта ул Тимерҗаннан да сорый.

— Нигә кирәк соң алар монда? — дип гаҗәпләнә Тимерҗан.— Беләсең килсә, тимер йөрәкле тимер зат булу—дөньяда иң зур бәхет ул! Бар кешеләр дә моңа ирешә алсыннар иде әле, сөенеп туймаслар иде. Бернинди дә хисләр, бернинди дә тойгылар кимереп ятмый җаныңны, рәхәтләнеп яшәргә комачауламый. Телисеңме син дә биредә калырга? Телисеңме мәңге үлмәс тимер йөрәкле тимер кеше булырга?

Коты алына Дамирның бу сүзләрдән, җаны өшеп китә. «Инде һичкайчан да өемә кире кайта алмам микәнни, әнидән гафу үтенә алмам микәнни?» — дип кара кайгыга төшә. Ләкин борчылуыңны тимер йөрәккә сиздерергә ярый димени? Йөрәге тимер булса да, күзләре бик очлы шул аның.

— Билгеле, телим, теләмәгән кая ул! — дигән була ул, бер-бер хәйлә белән барысын да белешмәкче булып.— Телим, әмма өемдә әнием белән әтием калды бит минем. Алар мине югалтканнардыр, мине юксыналардыр... Алар янына кайтып, алар белән хушлашып кына килергә мөмкин булмас микән миңа?

— Ә-ә-ә,— дип шунда ук Дамирга ябырыла Тимерҗан.—

Синең әле күңелеңдә әти-әниеңә карата шундый хисләр сакланганмыни? Юк инде, биредә бөтенләйгә калырга теләгән кешенең җаны туң, бәгыре таш булырга тиеш.

— Юк, юк! — дип кычкырып җибәрә шул чак Дамир җан ачысы белән.— Минем таш бәгырьле кеше буласым килми. Кирәге юк Тәңкә илегезнең, кирәге юк алтын тәңкәләрегезнең! Миңа әнием-әтием кирәк, миңа дусларым кирәк!

Әйтеп тә бетерүе була Дамирның бу сүзләрне, шунда ук Тимерҗан да, алтын тәңкәләр күкрәп үсеп утырган сәер кыр да, барысы, барысы да юкка чыга. Бераздан Дамир үзенең өенә әйләнеп кайтканын, үз бүлмәсендә идән уртасында басып торуын абайлап ала.

Өстәл уртасында торган акча тартмасын күреп алу белән, йөрәкләнеп, аны идәнгә бәреп ватасы килсә дә, үзен кулга алып өлгерә, тыелып кала. Гаепнең тартмада түгел, үзендә икәнен аңлый булса кирәк...

◆

ҚАРАҢГЫ ТӨНДӘ

Кечкенә генә бер шәһәр читендә, тын, аулак тыкрыкта, агач багана башында яшәгән, ди, Электр лампочкасы. Ул тормышны бик яраткан, шуңа да кич саен шатланып һәм куанып кабына икән. Чөнки шушы урамда яшәүче барлык кешеләрнең дә исән-имин өйләренә кайтып җитүләрен теләгән ул, шуңа күрә гел ярдәм итәргә тырышкан. Бигрәк тә кышларын һәм көзләрен, бозлы юлда таеп егылмасыннар, аяк-кулларын имгәтә күрмәсеннәр, пычракка бата күрмәсеннәр дип, бигрәк тә әйбәт яктырткан ул тирә-юньне. Дөрес, анда башка лампочкалар да булган булуын, әмма алар бу Лампочка кебек тырыш түгел, күбрәк моңа салыналар икән.

Ярый әле Лампочканы илһамландырып торучы булган: юл аша гына, каршысында гына үсеп утырган чибәр, яшь Қаен кызы икән ул. Лампочка аңа сокланып караган, Қаен кызы хәтта аның төшләренә дә керә торган булган. Бигрәк татлы булган ул төшләр!..

...Қыш көне була бу хәл. Бер заман кинәт көчле җил куба, буран котырына башлый. Башка лампочкалар тизрәк бер-бер артлы сүнеп бетәләр, безнең Лампочка бөтен тыкрыкта берьялгызы кала: кешеләр адаша күрмәсеннәр, юлдан язмасыннар дип борчыла ул, Қаен кызын да караңгы төн уртасында ялгызын калдырасы килми.

Шулай итеп, кешеләр барысы да өйләренә кайтып җитәләр, тәрәзәләрдә утлар алына, күңелле генә ашап-эчкәч, алар тынычлап йокыга китәләр.

Ә батыр Лампочка һаман яна, соңгы көчен җыеп булса да, буран эчендә әйләнә-тирәне яктырта ул. Чөнки, әгәр дә сүнсә, бөтен дөньяның дөм-караңгыда каласын белә. Ярый әле Қаен кызы үзен дәртләндереп тора.

— Син үзеңне йолдыз дип хис ит,— ди ул,— йолдызлар да бит әнә чиксез галәмне армый-талмый яктырта!

Лампочка, чыннан да, үзен йолдыз дип хис итә һәм таң якынлашып килгәндә инде тәмам хәлдән таеп, йолдыз сыман җем-җем итеп тора башлый...

Яктыргач, монтер абзый килеп, бар лампочкаларны тикшереп чыга. Калган бөтенесе шунда ук «ялт» итеп кабына, алар бит төне буе йоклап, ярыйсы гына хәл җыйган була. Ә безнең Лампочка, менә сүнәм, менә сүнәм дигән сыман, һаман җемелди дә җемелди...

Монтер абый, бераз башын кашып торганнан соң, үзен йолдыз дип хис иткән Лампочканы урыныннан борып ала да, аны башка, гап-гади лампочка белән алмаштыра. Ул аның нинди батыр Лампочка икәнен белми шул...

ОКЕАН ҺӘМ ТАМЧЫ

Би-ик күптән булган, ди, инде бу хәлләр. Бөек Океанның олы куенында яшәгән, ди, булган, ди, бер би-ик сылу Тамчы. Әмма үзе матур булса да, шундый назлы, шундый үзсүзле икән, хәтта мәгърур Океан белән дә каршы әйтешергә генә тора, ди. Гел үзенекен генә итмәкче була, ди. Ләкин мәһабәт Океан, Тамчыны өзелеп яратканга күрә, аның бар теләген дә берсүзсез үтәргә әзер тора, ди. Моны белгән Тамчы гүзәлнең башына көннәрдән бер көнне би-ик хәтәр бер уй килгән: ул Океан мәхәббәтенең көчен сынап карамакчы булган.

— Әгәр дә мәгәр син мине чынлап сөясең икән, исбат ит, аерыл башка бөтен тамчылардан да, җиткән инде аларга бер кайгы белми синең куенында яшәү! Бары тик минеке генә бул бүгенге көннән алып! — дигән ул катгый итеп.

Уйга талган акыл иясе бөек Океан, аптыраштa калган, бичара. Уйлап-уйлап торган да, соңыннан болай дип әйтеп куйган:

— Кадерлем Тамчы, соң син үзең яхшылап уйлап кара инде, ничек итеп аерылыйм мин алардан? Мин бит, Океан булсам да, үзем дә шул нәни тамчылардан торам, алардан башка мин дә юк, аңлыйсыңмы? Океан бары тик бер генә тамчыдан тора алмый, хәтта ул бик матур, бик чибәр булса да...

— Ә-ә, син шулаймыни әле?..— дип ярсып киткән үзсүзле Тамчы.— Алай икән, кал үзеңнең тамчыларың белән, ә мине син бүтән беркайчан да күрә алмассың!..

Яр буена тәгәрәп чыккан дулкыннарның берсенә ияреп, Тамчы ком өстенә тәгәрәп чыккан да шунда ук, ком бөртекләре арасына төшеп, мәңгегә эзсез югалган.

Ә бөек Океан, күңеле бик нык яраланса да, һаман шул Океан булып кала белгән.

◆

ЕРГАНАКНЫҢ МОҢ-ЗАРЫ

«Ерганак кеше түгел лә ул, аның нинди моң-зары булсын?!» — диючеләр дә табылыр, бәлки. Әмма бар шул Ерганакның зары, бик зур моң-зары бар шул аның.

Ерганак дигәч тә, мин дә бит дөньяга Ерганак булып тумаган идем. Мин — ярларын тутырып аккан, мул сулы гүзәл бер елганың аккан су юлы идем бит кайчандыр! Ә соңыннан ул елганың суы әллә кая китте, корыды, акрынлап аңардан бары тик Коры Елга дигән исем генә калды. Уйлап кына карагыз әле, нинди коточкыч, җан өшеткеч исем — үзе елга, ә үзендә бер генә тамчы да су калмаган...

Кайчандыр олы бер елга идем, ә хәзер суым корыды, Ерганакка әверелдем дип, башны ташка орып булмый, нихәл итмәк кирәк. Ерганак булып та яшәп буладыр ич дөньяда, дип уйлаган идем мин ул чакта. Һәм мин яши бирдем. Шуның өстенә, бер дустым — батыр балан агачы да минем күңелсез тормышымны бизәп, күңелемне җылытып тора иде.

Минем ярларым тоташ ком булганга күрәдер инде, анда бик сирәк үсемлек тамыр җәеп, үсеп китә ала иде. Ә менә кыю Балан орлыгы курыкмаган, бирегә очып килгән дә, көздән комыма күмелеп калып, язын шытып чыккан, тамырланып киткән. Тырыша-тырмаша торгач, бик тирәндә яткан суны да тамырлары белән суырып ала алган.

Менә быел ул, ниһаять, беренче мәртәбә чәчәк аткан, гранаттай янып торган җимешле бердәнбер тәлгәшен дә күрсәткән иде. Аңа карап мин дә сөенеп, куанып туя алмый идем. Аның тырышлыгына, матурлыгына, фидакярлегенә таң кала идем мин! Бәлки, ярларым да ул үсеп утырган урында ишелүдән туктар, бераз ныгый төшәр, дигән уй белән яши идем мин ул көннәрдә...

Шулай итеп вакыт уза торды. Менә инде җиргә беренче кар бөртекләре дә төшә башлады. Баланның җимешләре, беренче суыкларда куырылып, берникадәр бөрешә төшсәләр дә, әле һаман да матур иделәр.

Тик бер заман, көтмәгәндә-уйламаганда, безнең төбәкләрдә коточкыч фаҗига булып алды. Беркөн иртән иләмсез зур чүмечле бер сары машина әллә каян гына килеп чыкты да, ишелә-ишелә инде сөзәкләнеп беткән ярым буйлап төшеп, баланга якынлашты һәм аның янында шып итеп тукталып

калды. Бер җитез егет җәһәт кенә машинадан җиргә сикереп төште дә әллә нинди калын тимерчыбык элмәкне баланның кәүсәсенә кидертеп куйды. Аннары янә машинасына менеп утырды һәм аны үкертә-үкертә, тирә-юньгә сары төтеннәрен бөрки-бөрки, бар куәтенә мескен агачны тарта, йолкый башлады. Җан-фәрман тартышып карады баланым, әмма, билгеле инде, коточкыч зур машинаның тартуына озак каршы тора алмады, биреште: тамыры-ние белән минем үзәгемнән үк каерылып чыкты, бичара. Әле генә матур булып үсеп утырган урынында бары тик яра сыман ярылып яткан тирән чокыр гына калды. Шуннан соң машина аны сөйрәп, читкәрәк алып китте. Киткән юлында кан тамчыларына охшаган кып-кызыл җимешләре генә коелып калды баланның.

Аннары машина, әле генә балан үсеп утырган урында, чылбырлы тәгәрмәчләре белән минем комымны тырный-тырный, чокыр казый башлады. Ул да түгел, бирегә йөк машинасы да килеп җитте, сары машина аның кузовына минем комымны тутыра башлады. Ике шоферның үзара сөйләшүеннән сары комның нindидер төзелеш өчен кирәк булуын белдем мин. «Кирәктер инде, кирәктер,— дип уйладым мин шул чак, ачынып,— тик ни өчен соң әле алар бер урында төзиләр, ә икенче урында җимерәләр? Әллә минем җаным юкмы? Бәлки, алар бу турыда уйламыйлар, белмиләрдер? Ә бәлкем, күңелләре тундыр аларның? Күңелләренә кечкенәдән үк шәфкать орлыклары салынмагандыр?».

— Сез бит мине, күрә торып, тереләй харап итәсез! Туктагыз, җитте! — дип кычкырасым килде минем. Әмма без, ерганаклар, телгә килә, кычкыра алмыйбыз шул. Әрнүебез нинди генә көчле булса да, сабыр итәргә, түзәргә туры килә.

Күзләремне йомдым да, түземлегемне туплап, аларның үз эшләрен бетергәннәрен көтеп тора башладым. Әмма кешеләрне ничек кенә гаепләргә теләмәсәм дә, күңелем сыкрый, җаным рәнҗи иде минем. Боларына гына түгел, кайбер башка кешеләргә дә... Уйлап кына карагыз әле, ни өчен дип аларга минем ярларымны чүплеккә әйләндерергә, анда төрле юынтык сулары түгәргә кирәк инде?! Минем ярларым матур, нык булса, үзләренә дә рәхәт, күңелле булмас идемени? Ярдәм итсәннәр иде миңа: мине, Ерганакны, гүзәл бер төбәккә әверелдерсәннәр иде менә... Ә аларның башларына бу уй килеп тә карамый, ахрысы. Күңелләре гамьсез, күңел күзләре сукыр бу-

гай аларның... Хәер, бөтенесенеке дә түгел икән. Әнә минем би-ик күптәнге бер танышым, көтүче бабай, әллә кайчаннан бирле инде минем ярларыма төрле матур куаклар, хәтта сирень чәчәкләре дә утыртып, аны бизәргә уйлап йөри. Минем үземә дә сөйләгәне бар иде аның бу хыялы хакында. «Минә оныкларым гына кайтсын, әзерләп куйган үсентеләрем дә бар, шунда ук эшкә керешергә була...» — дигән иде ул, икегә аерылган кузы чикләвегенең тышын хәтерләткән күз кабакларын йома-йома. Тик нигәдер озаклады, һаман килми бабай. Бер-бер хәл булып куймагае үзе белән. Әгәр дә ул-бу килеп чыга-нитә калса, харап аннары минем эшләр. Харап... Киләчәккә булган соңгы өмет чаткым да сүнә инде аннары, ул килми калса...

◆

КОЯШНЫҢ ТУУЫ

Бу хәл инде бик күптән, ерак бер илдәге шәһәрдә булган. Әүвәл анда Төн патшасы хөкем сөргән. Ул чагында әле кояш та, ай да, хәтта йолдызлар да булмаган икән. Кара халык тычкан уты белән яктыртылган балчык йортларда яшәгән. Аннан алар бик сирәк чыккан, чөнки барыбер тышкы якта караңгы булган. Тамак туйдыру өчен әллә нинди сәер, гөмбә сыман үсентеләр үрчеткәннәр алар.

Елмаю-көлү, уен-күңел ачу, мәхәббәт-сөю — барысы да патша тарафыннан катгый рәвештә тыелган, гөнаһ саналган. Әкренләп халык кырыла, аның тамыры корый барган. Белмим, моның азагы ни белән бетәр иде, әгәр...

Бер заман шушы шәһәр янына, әллә каян гына килеп чыгып, ниндидер җырчылар, биючеләр төркеме туктаган. Шәһәргә аларны, билгеле, кертмәгәннәр, сакчылар капкаларны зур йозаклар белән бикләп куйганнар.

Җырчы-биючеләр шәһәр диварлары буенда учаклар ягып, ашлар пешереп, җырлап-биеп шактый ял иткәннәр. Учактан күтәрелгән очкыннар бик биеккә очкан, җырларның моңлы авазы еракларга таралган. Шул авазларның берсе шәһәрдә яшәүче Чаткы исемле кызның йөрәгенә кагылып узган һәм анда мәхәббәт уты кабызган. Ул күрше егете Ялкынга гашыйк булган. Үзенең сөюе белән кыз аның да йөрәген уяткан, алар бергәләп тормыш корып җибәргәннәр. Бераздан уллары да туган. Әти-әнисе малайга сәер һәм матур исем кушкан: аны Кояш дип атаган...

Шымчылар бу турыда Төн патшасына җиткергәннәр. И ачуы чыккан да инде патшаның! Кояшны калын таш диварлы зинданга бикләргә боерык биргән ул. Әмма Кояш йөрәгенең нурлары, калын диварларны үтеп, барыбер дөньяга бәреп чыккан. Әйтерсең ул нурлар халыкны Төн патшасына каршы көрәшкә күтәрелергә өндәгән.

Ләкин Төн патшасының бирешергә исәбе юк икән. Ул һаман явызлана барган, Кояшны хөкем итәргә әмер биргән.

Менә җәза көне килеп җиткән. Халыкны сарай алдындагы мәйданга куып китергәннәр. Зинданнан кул-аяклары богаулы

Кояшны алып чыгуга, тирә-юнь шундый да яктырып киткән! Төн патшасы, куркынып, кара йөзен каплаган, үзенең хезмәтчеләренә: «Тизрәк булыгыз!» — дип ишарә ясаган.

Менә вәзир тантаналы тавыш белән патшаның указын укыган, аннары шомлы итеп барабан кагуы ишетелгән... Җәллад үткен кылычын күтәреп селтәнүгә, Кояш шунда ук, бик нык пешереп, яндырып, талпынып куйган да, кинәт ялкынлы каурыйлы бер кошка әверелеп, биеккә омтылган. Күкнең иң биек ноктасына менеп җиткәч, тукталып калган һәм туган халкына, туып-үскән иленә җылы, назлы нурларын сипкән. Кояш шулай барлыкка килгән, имеш, ди.

◆



УМАРТА ҚЫЗЫ ҺӘМ ҮРМӘКҮЧ

Менә яз да килеп җитте. Умарта кызы өчен бу яз аеруча матур һәм гүзәл иде, чөнки бу — гомерендә иң беренче язы иде аның.

Чәчәктән чәчәккә очып, хуш исле бал җыйды ул.

Аның өчен бөтен дөнья гөл бизәкләре чигелгән дәү келәм сыман иде.

Умарта кызы иң матур, иң хуш исле чәчәкләрне генә сайлап кунды. Менә ачылып кына килә торган саф гөлчәчәк бөресе. Аңа әле бер генә бөҗәкнең дә кунганы юк. Яфракчыкларына таң үзенең бай төсмерләрен койган сыман, өсләрендә чык бөртекләре җемелдәп тора.

Умарта кызы, үзенең үтә күренмәле һәм сыгылмалы нәни гәүдәсе белән тыгыз яфракчыкларны аера-аера, чәчәкнең үзәгенә үрмәләде һәм яшеренеп яткан кечкенә алтын кояшка озын нечкә борынын батырып, татлы бал эчә башлады. Ул чиксез бәхетле иде.

Умарта кызы мәңге шулай дәвам итәр дип уйлаган иде,

әмма... ул ялгышкан икән. Җәй бәйрәме бик тиз узып китте, күз җитте. Бар чәчәкләр шиңде. Көне буе очып йөрсә дә, өенә бер тамчы балсыз кайта торган булды ул. Көзге кояш сүрелә барган шикелле, умарта кызының да йөрәге сүрелә барды.

Көннәрдән бер көнне кипкән кычыткан яфрагында каңгырып утырганда, күзенә ниндидер яктылык төшеп, күз алмасын кисеп үтте. Башын күтәреп караса — йа, хода!— саргайган агач яфраклары арасында төрле төсләр белән җемелдәп утырган көмешсу дәү чәчәкне күреп алды. Канатларын җилпеп, һавага күтәрелде, «чәчәк»кә кунып, борынын батырмакчы иде, борыны бушлыкка очрады. Һавага күтәрелеп, башка урынга кунмакчы иде, әмма тәпиләре үрмәкүч үргән пәрәвезгә инде ябышып өлгергән иде. Умарта кызы, үзәк өзгеч тавышлар чыгарып, безелди, бәргәләнә башлады. Әмма барысы да заяга: пәрәвезгә һаман ныграк кына урала барды ул. Кояш батканда, Умарта кызы тәмам хәлдән тайган, өметен өзгән иде инде.

Карт Үрмәкүч туганнары арасында иң чибәр, иң бай һәм иң дәрәҗәле санала иде. Ул ашыкмый гына оясыннан чыкты, коточкыч озын аяклары белән атлап, Умарта кызы янына якынлашты. Умарта кызын күреп, бер мәлгә аптырап калды. Чөнки гадәттә аның пәрәвезенә төрле чебен-черки генә эләгә иде, ә бу — матур, гәрәбәдәй янып торган гәүдәле, зур күзле, ә күзләрендә — никадәр моңсулык... Үрмәкүч үзенә күрә шагыйрь җанлы да иде. Әмма ятьмәсенә эләккән корбанын моңа кадәр әле бер генә мәртәбә дә азат иткәне юк иде аның. Җитмәсә, кичке аш вакыты җиткән, карыны ачкан иде. Ул Умарта кызына үзенең агуын сирпеде һәм оясына алып кереп китте...

Табигать-ана, бу фаҗигане күреп, Үрмәкүчнең явызлыгына түзеп тора алмады, ахрысы. Төнлә давыл купты, күк күкрәде, яшен яшьнәде, чиләкләп яңгыр койды. Бу гарасат эчендә Үрмәкүч тә котылып кала алмады, билгеле...

◆

ЧӘНЕЧКӘСЕЗ ГӨЛЧӘЧӘК

Чәчәк кибетендә, балчык чүлмәктә яшәгән, ди, бер Гөлчәчәк. Ләкин аның бер генә чәнечкесе дә булмаган. Шуңа күрә тирәсендә үсеп утырган гаҗәеп матур, хуш исле һәм... чәнечкеле гөлчәчәкләр аны бертуктаусыз рәнҗеткәннәр.

Ә чәнечкесез чәчәк күңелсез уйларына бирелгән дә, берни дәшмичә, алсу башын кыңгыр салып утыра бирә, ди. «Шушы чәнечкеле гөлләр арасында чәнечкеле сүзләр тыңлап гомерем заяга узып китәр микәнни? Ичмасам, бер генә көн, бер генә сәгать миңа бәхетле булырга язмаганмы икәнни? Шуның өчен генә туганмын микәнни мин?» — дип уйлана икән гөл. «Ә бәлки, берәр чәнечке үстереп караргадыр?» — дигән хәтәр уй да килеп киткән аның башына.

Тора-бара бичараның тормышы тагы да катлаулана төшкән. Зур корсаклы карт Кактус аңа димче итеп Үрмәле гөл карчыгын җибәргән. И мактаган димче карчык карт Кактусны, и үгетләп тә караган яшь, күркәм Гөлчәчәкне!

— Җүләр син! — дигән ул.— Син аның ямьсезлегенә карама. Аның каравы, күпме чәнечкесе бар! Ул сине беркемгә дә рәнҗетергә ирек бирмәс. Үз кадереңне үзең белмисең, тилекәй!.. Аннары, ул шактый кыйммәт тә тора, саткан чакта икегезне бергә сатарлар, бик зур бәхет бит бу!

— Соң, мин бит аны яратмыйм! — дигән Гөлчәчәк.

— Сиңа нинди ярату кирәк тагын? Синең гомерең бик кыска, тиздән шиңәрсең, беркем дә карамас үзеңә, шул турыда уйлар идең, ичмасам!

«Әллә күнәргә инде?» — дип уйлап алган Гөлчәчәк, әмма карт Кактусның, чәнечкеләренә күтәреп, аны үз өенә алып керүен күз алдына китерү белән, куркынып, ике кулы белән йөзен каплаган һәм җан ачысы белән: «Юк, юк, зинһар, кирәкми!» — дип пышылдаган.

— Ярый, алайса, көтеп утыр инде сөйгәнеңне,— дигән Үрмәле гөл һәм елан кебек шуышып китеп барган.

Ә икенче көнне кибеткә, хуҗасына ияреп, усал бер эт килеп кергән. Кергән дә, йөгереп барып, чәнечкесез Гөлчәчәкнең бер яфракчыгын умырып та алган.

И әрнегән Гөлчәчәк! Тән җәрәхәтләреннән битәр җан җәрәхәтләреннән сызланган ул. Инде гөлнең көннәре тоташ кара төнгә әверелгән. Шундый көннәрнең берсендә кибеткә олы яшьтәге бер абзый килеп кергән. Шунда ук аның күзе чәнечкесез Гөлчәчәккә төшкән. Ул аңа сокланып та, кызганып та озак карап торган, аннары, сатып алып, өенә алып кайткан. Анда ул Гөлчәчәкне киң бакчага, шундый ук чәнечкесез гөлчәчәкләр янына чыгарып утырткан.

Бакчада Гөлчәчәк үзенә тиң яр очраткан, алар, сөешеп, кавышканнар: бакчаны тутырып чәнечкесез нәни гөлчәчәкләр үстергәннәр.

◆

ИСКЕ МИЧ НИГӘ МОҢАЯ?

Тирән кар көртләре күмеп киткән ялан кыр уртасында, морҗамны күккә терәп утырган җирдән кинәт кенә бик ямансу булып китте әле. Тулган айның сагышлы нурлары астында шундый да күңелсез, авыр иде миңа. Күзләремне йома төшеп, уйга чумдым, еракта калган яшьлегемне исемә төшердем.

Йорт хуҗасы Рамазан шыгырдап торган нарат бүрәнәләрдән өр-яңа йорт салып кергәннән соң, шул өйне җылытып, ямьләндереп торыр өчен менә дигән мич кирәк булды. Андый мичне бары тик Рамазанның җан дусты, бабаларының бабаларыннан күчеп килгән борынгы һөнәр иясе, алтын куллы оста Мөбарәк кенә сала ала иде. Хуҗалар шушындый гозер белән нәкъ менә аның янына бардылар.

Мөбарәк ул — үз һөнәренең барлык серләренә, нечкәлекләренә төшенеп беткән осталар остасы гына түгел, ә бәлки үзенә күрә бер тылсымчы да иде. Серле тылсым көче аның кулларында иде булса кирәк.

Әле дә хәтеремдә: шул йомшак, җылы куллары белән бармакларга үзеннән-үзе сыланып, майдай ягылып торган балчыкны ул, камыр изгәндәге сыман, иркәләп чәбәкләп алды да, кинәт илһамланып, дәртләнеп китеп, авыр кирпечләрне кулларында уенчыктай уйната-уйната, баскан урынында бии-бии, күңеленнән ташып чыккан шатлыгын яшерә алмаудан җырлый-җырлый, эшкә кереште.

Эшне бик тиз түгәрәкләде Мөбарәк, ә соңыннан урта бер җиргә ялтырап торган көзге кисәге беркетеп куйды. «Әйдә, чагылдырсын әле үзендә кояш нурларын, аларны бөтен өйгә таратып, нур сирпеп торсын!» — дигәндер инде.

Мөбарәк оста кул җылысын гына түгел, җан җылысын да салып эшләгәнгә, гаҗәп тә матур, җыйнак һәм шәп килеп чыктым мин. Хуҗабикә ханым, толымнарына таккан чулпыхәситәләрен чыңлата-чыңлата, мичне ап-ак итеп акшарлады, аннары, шыңгырдап торган бер кочак каен утыны алып кереп, ут ягып җибәрде. Тәнемә, кайнар дулкын булып, җылы таралды. Ул җылыны мин, кирпечләремә сеңдереп калып, кадерле хуҗаларыма да өләшергә ашыктым.

Кичкырын миннән хуш исләр бөркеп торган бәлеш чыкты. Бәхетле ата-ана, өй тулы бала-чага өстәл яныннан кузгалып киткәч, Рамазан кулларына махсус эшләткән вараксин гармунын алды да минем янга, урындыкка килеп утырды, җитез

бармаклары гармунның сизгер телләре өстеннән йөгереп үтте һәм, өй эчен тутырып, моңлы халык көе агыла башлады...

Әле менә, шул көннәрне исемә төшереп утырган җирдән, кинәт күзләремне ачып җибәрдем, күз алдындагы шыксыз, үтә дә җансыз күренештән җаным өшеп киткәндәй булды.

Әле кайчан гына биредә зур бер авыл утыра иде, тормыш гөр килеп, кайнап тора иде. Кая китте болар барысы да, кая югалды? Иң беренче булып кемнәр ташлап китте соң әле туган авылын?

...Авыл таралып беткәч, алардан гайре авылда бер генә гаилә дә калмагач, Рамазан да үзенең йортын, бүрәнәсен бүрәнәгә таратып, сатып китәргә мәҗбүр булды. Йортны саттылар, үзләре калага киттеләр, ә мин япа-ялгыз калдым, кайчандыр биредә шаулап торган җанлы тормышның үкенечле бер истәлеге, хатирәсе булып калдым.

Кешеләр киткәч, табигать тә коргаксый башлады. Сайрар кошлар, әллә кайларга китеп, юкка чыкты. Чишмәнең дә суы төкәнде. Ак каеннарның да тамырлары корыды. Кеше кирәк иде шул барчасына, кеше кирәк иде...

Ничек инде шунда туып-үскән, шул җирнең суын эчкән, икмәген ашаган кешегә туган авылын ташлап китмәк кирәк? Еллар буе нәселдән нәселгә күчеп килгән һөнәреңне дә оныт, имеш, бабаларыңның бабаларыннан калган борынгы эш коралларын да чүплеккә чыгарып ташла... Моннан да аянычлы хәлне күз алдына китереп буламы соң? Нидер булган, ахры, кешеләргә, нидер булган. Әллә инде аларның күңел күзләре томаланган, берни дә күрми башлаганмы?.. Алай икән, аларның күңел күзләрен ничек тә ачтырасы иде бит! Жиде төн уртасында татлы йокыларыннан бүленеп, сискәнеп уянсыннар да, дөньяларын онытып, очар кошлардай булып, төрлесе төрле яктан очып кайтсыннар иде! Менә шәп булыр иде, менә күңелле булыр иде шулчакта!

Шулай уйланып, татлы хыялларга бирелеп утырганда, күз алдыма янә бик сагынылган, бик тансыклаган нәрсәләр килеп басты. Менә хуҗабикәм, җырлый-җырлый миндә ут тергезеп йөри, имеш. Тәмле бәлеш салырга җыена, имеш, хуҗа ханым. Ә минем эчтәге утын шытыр-шытыр яна, имеш. Морҗамнан төтен, мул булып бөркелеп чыгып, биеккә, күккә күтәрелә дә, аннан, биектән, авылдашларга, якташларга үзенең зәңгәр кулъяулыгын болгый, имеш...

МӘҢГЕЛЕК ХӘРӘКӘТ

Яз килү белән, дөнья шау чәчәккә күмелгән һәм бер Чишмәнең куенында Тамчы туган. Бигрәкләр дә шук, чая булган, ди, ул. Сикерә-сикерә уйныйсы, әллә кайларга китәсе килгән аның. Менә ул, Чишмә суына кушылып, түбәнгә, инешкә таба атылган, шул су белән бергә еракларга агып киткән. Хәтта үзен тудырган Чишмә белән дә рәтләп хушлашырга оныткан Тамчы.

Баштарак инеш, вак-вак ташлар өстеннән уйнаклый-уйнаклый, күңелле генә җырлый-җырлый аккан. Тора-бара инде аның як-якларында үзенә күрә ярлар да барлыкка килгән, ул һаман тирәнәя, киңәя барган һәм, ниһаять, ургылып, киң далага килеп чыккан, җәелеп китеп, мәһабәт Елгага әверелгән. Хәзер инде аның ярларында күкрәп үсеп утырган яшел урманнар калкып чыккан, таллык-әрәмәлекләр, болынлыклар пәйда булган. Елга тырышып-тырышып хезмәт итәргә керешкән: кырларны сугарып, уңыш үстергән, дәү кораблар йөрткән; турбиналардан үтеп, су яктылыкка әверелгән.

Шулай озак дәвам иткән, ди. Әмма бер заман елга кинәт ашкынып, алга омтыла башлаган. Сөйгәне Диңгезнең чакыруын ишеткән шул ул. Күп тә үтмәгән, алар очрашканнар, кавышканнар, ди.

Шулай итеп, безнең Тамчыбыз да Диңгез тамчылары белән бергә кушылган, Диңгез суына кереп югалган, шунда яши башлаган, ди. Ә шулай да үзен тудырган Чишмә җырын онытмаган ул, һаман исендә тоткан, туган ягын сагынып, гел шул җырны көйләгән. Бик моңлы, бик матур булган шул аның җыры, шуңа күрә Кояш үзе дә аны яратып, онытылып тыңлаган, ди. Тамчының күңелен аңлаган, аны кызганган булса кирәк мәрхәмәтле Кояш. Көннәрдән бер көнне ул, бер нурын сузып, аны Диңгездәге башка тамчылардан аралап, күктән йөзеп барган болытларның берсенә салган, имеш. Талгын җил, әкрен генә исеп, ул болытны Тамчының туган якларына алып киткән, ди.

Тамчы өенә кайтып җиткән чакта, болыт инде тәмам куерган, кабарынган була. Нәкъ Чишмәнең өстендә туктый да, яңгыр булып ява, шифалы суларын сибә. Шул сулар белән бергә Тамчы да Чишмәгә тама, янә үзенең газиз әнкәсе белән кавыша.

И-и сөенәләр инде болар, серләшеп, сөйләшеп туя алмыйлар! Күпмедер вакыт шулай узып та китә. Тик бераздан Тамчы тагын борчыла, тынгысызлана башлый, аның күңеле яңадан каядыр еракларга ашкына башлый. Бу турыда ул әнкәсе Чишмәгә дә сөйләп бирә.

— Бер дә исең китмәсен! — ди Чишмә кызына.— Бу — табигый хәл. Син буйсынырга тиеш. Чөнки син — бәләкәй генә Тамчы, синең язмышың — мәңгелек хәрәкәт, балам... Әгәр син хәрәкәтләнүдән туктасаң, барлык табигать моны шунда ук сизеп алыр, агач-куаклар корыр, гөлләр шиңәр, җәнлекләр кырылыр, дөнья, корылыктан интегеп, ком чүленә әверелер. Ә син хәрәкәттә булганда, табигать тә, барлык тереклек ияләре дә мәңге яшәр, мәңге яшь булыр...

Шулай итеп, Чишмә Тамчыны яңадан озын юлга озатып калган. Тамчы күздән югалганчы, аңа зәңгәр кулъяулыгын болгаган...

◆

ДАВЫЛ КОШЫ

Борын-борын заманда, биек таш кыя башындагы ояда нәни генә бер кошчык дөньяга туган. Ул — Давыл кошының күз карасыдай күргән газиз баласы булган, ди. Ай үсәсен көн үскән бәләкәч, шул биеклектән, оядан иксез-чиксез диңгез киңлекләренә, очсыз-кырыйсыз күкләргә карап, анда канат какмый гына очкан башка дәү кошларга карап, үзе дә, тизрәк үсеп җитеп, очарга, зәңгәр киңлекләрне иңләргә хыялланган.

Канатлары ныгый төшкәч, әткәсе белән әнкәсе аны очарга өйрәтә башлаганнар. Давыл кошы көннән-көн биеккәрәк күтәрелә, һаман ераккарак оча башлаган. Ниһаять, көннәрдән бер көнне, күкнең иң биек ноктасына менеп җитү бәхетенә ирешкән ул. Шул чак үзе дә мәгърур бер кошка, Давыл кошына әверелгән, ди.

Шулай матур гына яшәп яткан чакта, көтмәгәндә-уйламаганда, диңгез өстендә коточкыч давыл купкан. Куе кара болытлар зәңгәр күкләрне бөтенләй томалап, камап алган, ди. Әледән-әле ялт та йолт яшен камчылары ялтырап киткән, бөтен җиһанны дер селкетеп, дөбер-дөбер күк күкрәгән. Көчле җил, дәү-дәү дулкыннарны күтәреп алып, болытларга хәтле ыргыткан. Ләкин Давыл кошының йөрәге куркуның ни икәнен дә белмәгән, чөнки ул гаять батыр, гаять кыю кош икән. Ул бары тик болытлар томалап алган Кояшны гына кызганган, аның язмышы хакында борчылудан йөрәге сызган. Өзелеп сөйгән Кояшына ничек тә ярдәм итү чарасын эзләгән Давыл кошы.

Менә ул, озак та уйлап тормастан, уттай янып торган карашын кара болытларга төбәгән дә, дәртле, көчле тавышы белән аваз салып, чиктән тыш дуамал батырлык белән Кояшны урап алган кара болытларга каршы ташланган, аларга таба атылып менеп киткән. Болытларны җиңеп, Кояшны коткару булган инде аның уе. Әмма ләкин яраткан Кояшы янына менеп җитә алмаган шул Давыл кошы: яман чытырдап ялтырап киткән яшен угы, ялкынлы ук, аның йөрәгенә үк кадалган, ди. Ялкын шунда ук Давыл кошының каурыйларына, канатларына үрләгән. Дөрләп яна-яна, аваз сала-сала, Давыл кошы юлын дәвам иткән, һаман биеккәрәк күтәрелә барган. Ул биеккәрәк күтәрелгән саен, әле күптән түгел дөм-караңгылыкта калган дөнья һаман яктыра, нурлана барган. Моны күреп,

бүтән кошлар да өерләре белән Кояшка таба юл күрсәтеп баручы батыр йөрәкле Давыл кошы артыннан омтылган. Бик күпләре табигать көчләре белән булган ул тиңсез көрәштә башларын салган, бик күпләренең гәүдәләрен төпсез упкын йоткан. Бары тик берничәсенә генә максатларына ирешү насыйп булган. Алар, кара болытларның тоташ калын пәрдәсен ертып, Кояшның үзен күрү бәхетенә ирешкәннәр. Шул чак Кояш үзе дә, куе болытларны аралый-аралый, җир йөзенә җылы карашын ташлаган, ягымлы итеп бер елмайган.

Шулай итеп давыл әкренләп тына барган. Бераздан инде су өстендә дә, җир йөзендә дә гаҗәеп тынлык урнашкан. Бар нәрсә дә нәкъ элеккечә икән, бары тик Давыл кошы гына юк, ди. Күп кенә кошларның очып йөрүләренә карамастан, күк йөзе дә аңардан башка буш кебек икән, диңгез дә аны юксына икән. Юксынуына түзә алмыйча, ул яшәгән таш кыяның итәгенә дулкыннарын чупыр-чупыр бәрә-бәрә, һаман сагышлана, һаман ямансулый икән диңгез, Давыл кошыннан отып алган көен һаман көйли, һаман җырлый икән...

ЭЧТӘЛЕК

Ак күгәрчен 3
Мәк чәчәге һәм Тигәнәк 6
Сандугач һәм Саескан 9
Үлмәс гөл 12
Қар катламы 16
Яшь бөртеге 18
Курай моңы 22
Тәңкәбикә 24
Қараңгы төндә 29
Океан һәм Тамчы 31
Ерганакның моң-зары 32
Қояшның тууы 35
Умарта кызы һәм Үрмәкүч 37
Чәнечкесез Гөлчәчәк 39
Иске мич нигә моңая? 41
Мәңгелек хәрәкәт 43
Давыл кошы 45

Издание для детей и юношества

Аглиуллина Фирдаус Асадулловна

БЕЛАЯ ГОЛУБКА

Сказки-новеллы

(на татарском языке)

Рецензенты **Х. Гайнетдинов**
Редакторы **Ф. Зыятдинова**
Художнигы **Н. Хаҗиәхмәтов**
Художество редакторы **Ф. Хәсьянова**
Техник редакторы **М. Абитова**
Корректоры **Р. Хәмидуллина**

ИБ № 5465

Җыярга тапшырылды 24.02.89. Басарга кул куелды 11.03.90. ПФ 09044. Форматы $70\times90^{1}/_{16}$. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 3,51. Шартлы буяу-оттиск 4,68. Нәшер-хисап табагы 2,28. Тиражы 30 000 экз. Заказ Б-96. Бәясе 10 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.



10 тиен